ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**"Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында" 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 26 статьяның 1 пунктына "Татарстан Республикасы Прокуратурасы" сүзләреннән соң ", Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы" сүзләрен өстәргә;

2) 45 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.";

3) 47 статьяның җиденче абзацына "Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары," сүзләреннән соң "Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы," сүзләрен өстәргә;

4) VIII бүлек исемендә **"ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ,"** сүзләреннән соң **"ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР СОВЕТЫ,"** сүзләрен өстәргә;

5) 55 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"55 статья. **Республика башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы, җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге**

1. Республика башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары үз эшчәнлекләрен районнар, республика әһәмиятендәге шәһәрләр территорияләрендә җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашыралар, аларның үтенече буенча эшчәнлекләрен гамәлгә ашыруда тиешле ярдәмне күрсәтәләр.

Республика башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара хезмәттәшлек итәләр.

2. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы, җирле үзидарә органнары теләсә кайсы республика башкарма хакимияте органына һәм аның территориаль органнарына алар карамагындагы мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәргә хокуклы.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2015 елның 1 июле
№ 46-ТРЗ